# Казан федераль университеты

DARELFØNYN
УНИВЕРСИТЕТ
абитуриентлар өчен
махсус чыгарылыш

№ 14 (27)
28 апрель 2012 ел

## КФУ – ул...

*«Бүген Казан университеты – Татарстан Җөмһүриятенең югары белем өлкәсендә әйдәп бара торган уку йорты. Ул, Россиянең борынгы мәгариф үзәге буларак, бөтен дөньяга билгеле».*

Рөстәм Миннеханов,
ТР Президенты

*«Минем онытылмаслык студент елларым искиткеч тарихы һәм бөек галим-мөгаллимнәре булган диварлар кысасында үтте. Университет Казан шәһәре тормышында мөһим урын алып торды, бүген дә, алга таба да шулай булачагына ышанам».*

Илсур Метшин,
Казан шәһәре мэры,
юридик факультетның 1992 елгы
чыгарылыш студенты

*«Танылган университет, бөек тарих, күренекле галимнәр, якты киләчәк! Минә нәрсә ул – Казан федераль университеты! Уңышлар Сезгә!»*

Рөстәм Хәмитов,
БР Президенты

*«Ике гасыр дәвамында Казан университеты РФнең иң эре фән, белем бирү һәм мәгариф үзәге булып тора. Университет коллективы югары белем системасының һәм Казан фәнни мәктәбенең традицияләрен саклый, яңарта, интеллектуаль һәм ресурс потенциалын үстерә. Казан университетының данлы үткәне һәм бик яхшы киләчәге бар!»*

Фәрит Мөхәммәтшин,
ТР Дәүләт Советы рәисе



www.kpfu.ru
чыгарылышның тулы мультимедиа-version
UNIVERSMOTRI.RU
рубрика «абитуриенту»

## Хөрмәтле чыгарылыш сыйныф укучылары!

Хәзер сез: «Алга таба кая барырга?» – дигән сорауга җавап эзлисез. Шушы авыр чорда дөрес юл сайларга кирәк. Ул киләчәктә, һичшиксез, җәмгыять өчен файдалы белем булырга тиеш.

**208 ЕЛЛЫК** ТАРИХЫ булган Казан университеты һәрвакыт актив, төпле белем алырга теләүче яшьләрне үзенә җәлеп итә. Ә федераль университет дәрәҗәсенә җиткәч, уку йортыбызның мөмкинлекләре тагын да артты. Бездә заманча белем генә түгел, ә реаль икътисад, IT-тармак, банк эшчәнлеге, идарә итү структурасы буенча өстәмә белем һәм күнекмәләр дә бирелә. Безнең университетта табигый-фәнни һәм гуманитар юнәлештә белгечләр әзерләү өчен, барлык мөмкинлекләр дә каралган.

Нигезе Казан университеты булган федераль уку йорты республикабызның берничә алдынгы вузын берләштерде. Аның базасында **16 ИНСТИТУТ ҺӘМ 5 ФАКУЛЬТЕТ оешты**. Шуларның Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты, Идарә итү һәм территориаль үсеш институты, Икътисад һәм финанс институты, Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты, Мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати системаларның югары мәктәбе, Югары банк мәктәбе һ.б. яңа ачылган бүлекләрдән санала. Гомумән, бирелә һәркем күңеле теләгән юнәлешне сайлый ала. Бүген белем бирү юнәлешләре заманча фән, техника һәм алдынгы җитештерүчәнлек хисабына шактый киңәйде. Бу аеруча да кара алтын-газ эшкәртү, гамәли информатика, картография һәм геоинформатика, нанотехнологияләр һәм микросистемалы техника, техник физика, эшмәкәрлеккә бәйле информатика, социаль-мәдәни сервис һәм туризм, чит ил төбәкләрен өйрәнү һ.б. өлкәләргә карый.

Казан федераль университеты студентлары өчен Россия һәм чит илләрнең әйдәп баручы фән-белем бирү үзәкләрендә стажировка үтү мөмкинлеге бар.



Татьяна көне. 25 гыйнвар, 2012 ел

Ә аспирантурада укуларын дәвам иткән очракта, безнең һәм чит ил фәнни җәмәгатьчелегенең рәсми рәвештә тануына ирешә – фән кандидаты һәм Көнбатыш илләре югары уку йортларында кабул ителгән Phd дәрәҗәсенә ия була алалар.

Университетта фән, җәмәгать эшләрендә, спорт һәм мәдәни чараларда актив, инновацион идеяләр конкурсларында җиңү яулаган студентларны матди яктан тәэмин итү буенча күп эшләр башкарыла. **АНДЫЙЛАР 5 МЕҢНӘН 25 МЕҢГӘ** КАДӘР ректор стипендиясенә ия була. Читтән килеп укучы студентлар 100% тулай торак белән тәэмин ителә, спорт белән шөгыльләнү өчен, заманча җиһазландырылган корылмалар эшли.

Казан университетының үзенә җәлеп итүе 2011 елда укырга Россия Федерациясенең **48 ТӨБӘГЕННӘН (ИЛЕБЕЗ СУБЪЕКТЛАРЫНЫҢ 60%)** студентлар кабул ителүдән дә күренә.

Әгәр дә син талантлы, һөнәр үзләштерүдә һәм тормышта максатларың бар, якты индивидуальлек булдырырга телисең икән, сине нәкъ менә Казан федераль университеты көтә. Биредә белем алу лаеклы киләчәк төзүдә уңышлы башлангыч булсын!

**Илшат ГАФУРОВ,**
**КФУ ректоры**

## Укырга ничек керәбез?

### Кабул итү комиссиясенә документларны берничә төрле юл белән тапшырырга мөмкин:

- Шәхсән үзең КФУның кабул итү комиссиясенә килеп (Казан, Кремль урамы, 35 йорт, II корпус, 114, 115, 116 бүлмәләр; ☎ 8(843) 292-73-40, 233-70-76) гариза язарга;
- 10 июльдән дә калмыйча, кирәкле документларның күчермәләрен почта аша юлларга була. Адрес: 420008, Казан, Кремль урамы, 18 йорт, КФУның кабул итү комиссиясенә;
- гаризаларны 20 июньнән 25 июнь аралыгында abiturient.ksu.ru электрон сайты аша да җибәрергә мөмкин;
- документларның төп нөсхәләрен (аттестат, 3х4 форматындагы 6 фото, ИНН күчерелмәсе, иминиятләштерү таныклыгы, паспорт, полис күчерелмәләре) кабул ителүчеләрнең исемлеге чыкканчыга кадәр дә, исемлек чыккач та китереп бирергә мөмкин;
- әгәр дә Казанга шәхсән үзегез килә алмасагыз, документларны, 10 июльдән дә соңламыйча, почта аша җибәрергә кирәк;
- нинди дә булса ташламаларга ия булучылар шәхсән үзләре килергә тиеш!

### Сайтларда актарынабыз!

Сезгә һәр институт-факультетның сайт адресын тәкъдим итәбез. Тулырак мәгълүматны һәм яңалыкларны сез биредә таба аласыз!

- Биология һәм туфракны өйрәнү факультеты ksu.ru/f1/index.php
- Экология һәм география институты ksu.ru/f2/index.php
- Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты ksu.ru/f3/index.php
- Тарих институты ksu.ru/f4/index.php
- Н.И.Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институты ksu.ru/f5/index.php
- Физика институты ksu.ru/f6/index.php
- А.М.Бутлеров исемендәге Химия институты ksu.ru/f7/index.php
- Юридик факультет ksu.ru/f8/index.php
- Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты ksu.ru/f9/index.php
- Филология һәм сәнгать институты ifi.kpfu.ru
- Журналистика һәм социология факультеты ksu.ru/f13/index.php
- Икътисад һәм финанс институты kgfei.ru
- Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара бәйләнешләр институты ksu.ru/f16/index.php
- Педагогика һәм психология институты ksu.ru/i17/index.php
- Фәлсәфә факультеты ksu.ru/phil
- Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты ksu.ru/ifksivm/index.php
- Идарә итү һәм территориаль үсеш институты ksu.ru/f14/index.php
- Яшел Үзән филиалы green.ksu.ru/main.asp
- Яр Чаллы филиалы fksu.ru
- Алабуга филиалы egpu.ru/main/default.aspx

## КФУ – ул...

*«Россиядә бай тарихлы уку йорты – Казан университеты дөньякүләм фән өлкәсендә зур урын били. Аның Лобачевский кебек танылган галимнәре тарих битләренә алтын хәрефләр белән язып куелды. Бүген дә шундый яхшы белгечләр әзерләвегезне телим».*

Әхмәтбәк Килдебәков,
Кыргызстан Республикасы
Парламенты рәисе

*«Мин Казан университетының мактаулы докторы исемен зур горурлык белән йөртәм. Казан Россия һәм Татарстанның мәдәни, фәнни һәм сәяси тормышында бик мөһим роль уйный».*

Абдуллаһ Гөл,
Төркия Президенты

### Үсеш юлында – 8 өстенлекле юнәлеш:

- яңа материаллар һәм нанотехнологияләр;
- мәгълүмати-коммуникацион технологияләр;
- биология, медицина һәм тере системалар технологиясе;
- табигатьтән рациональ файдалану;
- күп дәрәҗәле мәгариф системалары, гуманитар һәм педагогик технологияләр;
- мәдәниятара коммуникацияләр, Көнчыгышны өйрәнү, төбәк һәм халыкара мөнәсәбәтләр;
- төбәкнең социаль-икътисади үсеше, алдан күрү һәм идарә итү технологияләре;
- кара алтын-газ технологияләре.

# Чын студент тулай торакта яши!

Зилә ФӘСХИЕВА



Студент еллары – хатирәләргә бай чор! Әгәр дә бу елларны студентлар тулай торагында үткәрергә туры килсә, син икеләтә бәхетле дигән сүз! Яңа дуслар, күңелле тормыш, берне дүрткә бүлеп ашау, бәйрәмнәр, бергәләп үткәрелгән туган көннәр – һәммәсе дә тулай торак «җимешләре»! Безнең тулай торакләр **Пушкин, Кызыл Позиция, Гадел Кутуй, Бутлеров һәм Парин урамнарында урнашкан. I курска килүчеләрне, гадәттә, Универсиада авылы (Парин урамы) көтә.** Студентлар тулай торак белән **100%** тәэмин ителә.

Академик Парин урамында урнашкан «авылда» йортларның эче бик матур, якты, бар җиһазлар яңа, пластик тәрәзәләр тавыш үткәрми, шәһәр шаукымыннан ерак торасың – бик тыныч. Төрле катка лифт ярдәмендә менәсең. Бүлмәләрдә 2-3 кеше яши. Бүлмә саен душ бар. Аш бүлмәсе 3-4 бүлмәгә бер. Кондиционер, Интернетка керү өчен мөмкинлекләр каралган. Куркынычсызлык өчен дә борчылыр урын юк: коридорлар видеокамера белән тәэмин ителгән. Тулай торак билгеле бер вакытта бикләнә. 11 дән 6 га кадәр шаулап йөрү юк.

Универсиада авылында 24 сәгать буе эшли торган **даруханә бар, кибетләр якын** (киләчәктә ишегалдында да кибет ачарга ниятлиләр), **бассейнга, тренажёр залларга йөрү, тимераякта шуу** (ишегалдында) кебек мөмкинлекләр каралган. Ә җәй көне **велосипедта, роликларда йөрергә** (кулланып торырга бирәләр), **теннис, футбол уйнарга була.** һәр бәйрәм саен төрле кичәләр, психолог белән очрашулар, дискотекалар үткәрәләр, кунаклар еш килә.

Пушкин урамындагы ике Студентлар йорты инде күптән төзелгән. Шуңа карамастан, алар укучыларның яраткан тулай торaклары булып санала. Бердән, **үзәктә** урнашкан, **укырга җәяү йөрергә** мөмкин. Икенчедән, барлык уңайлыклары да бар, чиста. Тулай торакка теләсә-кем кереп йөри алмый, 23.00-6.00 аралыгында бикле була. Башка тулай торaкларлагы кебек **үк бер айга түләү суммасы 60 сум** тәшкил итә.

Кызыл Позиция һәм Гадел Кутуй урамнарында урнашкан тулай торакны үз студентлары шулай ук бик ятаталар. Студентлар үзара дус-тату яшиләр. Бүлмә һәм этажлардагы чисталыкны студентлар һәрдаим кайгыртып тора.

Бутлеров урамындагы тулай торакта Финанс-икътисад институты студентлары яши. Ул университет бинасына бик якын булуы белән аерылып тора, хәтта янәшәсендә дияргә була. Дисциплина, кагыйдәләр башка тулай торaклардагы кебек үк.

Һәр тулай торакка урнашканда, билгеле бер документлар булырга тиеш.

Алар түбәндәгеләр:

- **паспорт копиясе (фото һәм прописка битләре);**
- **3х4 форматындагы ике фото;**
- **кан анализы нәтиҗәләре (RV);**
- **прививкалар турында сертификат;**
- **флюорография күчермәсе;**
- **«тулай торакта яшәргә ярый», дип, терапевт биргән белешмә.**

Һәм иң мөһиме: тулай торак законнарына беркайчан да каршы бармаска кирәк! Әгәр дә үзеннең йөзең ачык булса, сиңа да һәрдаим ярдәм итеп торачаклар!

UNIVERSMOTRI.RU



Универсиада авылында: аш бүлмәсе



...керләрне «килен» юа, үтүкләсе генә кала



...студентларның ял почмагы

абитуриенту /вот моя деревня kpfu.ru/main_page?p_cid=5699&p_sub=9644

Материалларны Динара ӘХМӘТОВА әзерләде

# Һөнәр күккә җиткерер...

Бүгенге көндә Россиядә – меңләп, Казан югары уку йортлары каршында 80 гә якын кече инновацион предприятие эшли. Алар галимнәрнең фәнни эшләнмәләрен коммерцияләү һәм керем алу максатын тормышка ашыра. Казан федераль университеты каршында да 22 кече инновацион предприятие бар.
new.kpfu.ru/main_page?p_cid=947&p_sub=



Казан университетының **биохимиклары** агрессияне төкерек ярдәмендә билгели. Моның өчен кешегә тест-тасманы ялап алу җитә. КФУның биохимия кафедрасы доценты Әлфия Фәттахова уздырган тикшеренүдә психиатрия пациентлары да, полиция мәктәбендә белем алучылар да, мәктәп укучылары да катнаша. Наркотик кулланучыларның 67%ында махсус фермент (фәнни телдә «моноаминоксидаза А» дип атала) бик түбән дәрәҗәдә, шуның аркасында кеше наркотикларга тартыла икән. Мәктәп укучыларының исә якынча 7% агрессия белән интегә. Ул тора-бара депрессиягә әйләнә. Бүгенге көндә әлеге тест-тасманы күпләп чыгаруга әзерлек бара.
ksu.ru/univer_tv/video/video.phtml?uniq=112
http://www.kpfu.ru/main_page?p_sub=9927

**«НаноКАМРИ» предприятиесендә** наноагрегат комплекслар нигезендә магнит-резонанс томография сурәтләренең каршылыгын арттыра торган композицияләр житештерелә. Металлокомплекстагы концентрацияне киметү хисабына, токсиннарның пациент организмына тәэсире дә кими. Бүген бирегә токсикологик тикшеренүләр уздырыла. Шулар нәтиҗәсендә хайваннарга диагноз кую өчен каршылыклы МРТ-агентлар булдыру эше бара. ksu.ru/uir/mip.php№

**«ГенДжин» предприятиесендә** куркыныч авыруларны дәвалау өчен, ген-терапевтик дарулар әзерлиләр. Препаратларны нейродегенератив, йөрәк-кан тамырлары авырулары вакытында, үзәк һәм периферик нерв системасына зыян килгәндә, пешү очракларында кулланырга мөмкин. ksu.ru/uir/mip.php№

# Чикләр киңәя

Казан федераль университеты үз чикләрен киңәйтүне дәвам итә. Аның составына яна уку елыннан тагын бер уку йорты кушылачак. Бүгенге көндә Тольятти шәһәрендәге В.Н.Татищев исемендәге дәүләтнеке булмаган Волжск университеты КФУның Тольятти институты булачак.




Университетның фәнни-мәгариф корпусы Жигулёвск шәһәрендә урнашкан. Анда 51 кешелек тулай торак, махсус һөнәри белем бирү колледжы, китапханә, укытисад һәм юридик факультетның читтән торып уку бүлекләре бар.

Тольяттида уку йорты 3 корпустан тора. Төп бинада вузның горурлыгы – шәхси криминалистик полигоны, мультимедиа һәм лекцион аудиторияләре булган юридик факультет урын алган. Мәгълүмати технологияләр факультеты урнашкан бинада 800 дән артык студент компьютер һәм телекоммуникацион эшләнмәләр белән бәйле белгечлек алырга әзерләнә. Эшмәкәрлек өлкәсенең куркынычсызлыгы үзәгендә мәгълүмат һәм технологияләрне саклау эше алып барыла. Шулай ук студентлар белемнәрен экологик лабораториядә дә арттыра ала. Аеруча актив һәм иҗади студентлар өчен «Укудан тыш эшчәнлек» үзәге, нәшрият һәм телестудия эшли.

Әлеге кушылу ике як өчен дә файдалы. КФУ Татарстаннан читтә үз эшчәнлеген башлап җибәрсә, Тольяттиның В.Н.Татищев исемендәге Волжск университеты өчен зур мөмкинлекләр ачылачак.

# Бергә-бергә!

Казан университетының тестлар үткәрү һәм бердәм дәүләт имтиханына әзерли торган укыту-методик үзәгенә 2011 ел ахырында 5 ел тулды. Бүгенге көндә ТР һәм Идел буе федераль округы университетлары структурасында мондый инновацион юнәлештә эшли торган башка үзәк юк.
Үзәк ике дистәдән артык проектны тормышка ашыра: **әзерлек курслары, дистанцион укыту, БДИга әзерләнү өчен методик кулланмалар эшләү, укучылар өчен сынап карау имтиханнары, интернет-олимпиадалар уздыру һ.б.** Курсларга белеме төрле дәрәҗәдә булган укучылар йөри ала. Укытучылар дәресне көчле укучылар өчен дә, белеме бераз түбән булганнар өчен дә аңлаешлы итеп уздырырга тырыша. Нәтиҗәдә команда туплана, «белемле-белемсез», дип аерып карау бөтенләй юкка чыга. Үзәк укытучылары БДИга төркемләп әзерләнүнең тагын бер унай ягын күрсәтә: укучыларда үзара көрәш дәрте барлыкка килә һәм алар артта калудан курка.



Үзәкнең мактанырлык уңышлары да шактый: 5 ел эчендә **БДИга әзерлек курсларын 3100 укучы тәмамлаган**. Бүген 37 төркемдә 500 дән артык укучы укый. Сынап карау имтиханын 15 меңнән артык укучы тапшырган, 9 методик кулланма бастырылган.
Үзәкнең тагын бер уңышлы эш алып бара торган юнәлеше – **интернет-проектлар.** «Студент булачакмын» («КФУ абитуриенты») социаль-белем бирү челтәре бер ел эчендә яхшы күрсәткечләргә ирешә. Бүгенге көндә анда 200 меңнән артык кулланучы теркәлгән. 2011 елда КФУ уздырган интернет-олимпиадаларда РФнең 38 төбәгеннән 14 меңнән артык укучы катнашкан.

N.B. Гаризанны abiturient.kpfu.ru электрон сайты аша җибәрсән, рәсемдәге «чират тору» хәленә калмаячаксын!☺

Материалларны Динара ӘХМӘТОВА әзерләде

ҺӨНӘР САЙЛАУ – ТОРМЫШКА ЗУР СУКМАК САЛУ УЛ. ҺӘР КЕШЕ ҮЗ АЛДЫНА: «МИН КЕМ БУЛЫРГА ТЕЛИМ ҺӘМ КЕМ БУЛА АЛАМ?» – ДИГӘН СОРАУ КУЯРГА ТИЕШ. БУ КАТЛАУЛЫ СОРАУГА СИН ГЕНӘ ЖАВАП БИРӘ АЛАСЫН. ӘТИ-ӘНИ, ТУГАННАР, ДУСЛАР СИНА НИНДИДЕР ЮНӘЛЕШ КЕНӘ БИРЕРГӘ МӨМКИН. БЕЗ ДӘ СИНА КҮПМЕДЕР ЯРДӘМ ИТӘ АЛЫРБЫЗ.

# «Телим» һәм «була алам»


**Физиклар – лириклар...**

**Физика институты - ул:**

- **инновацион белем;**
- **төрле юнәлеш буенча әзерләнүче белгечләр;**
- **фәнни җиһазларның заман паркы;**
- **Россиядә һәм чит илләрдә югары хезмәт хакы;**
- **төпле белем һәм киләчәккә тагын бер ышанычлы адым дигән сүз.**

Үз язмышын физика өлкәсе белән бәйләгән кеше беркайчан да үкенмәячәк. Ә Физика институтында укучы студент елларын гел сагынып яшәячәксен. Шул күнелле елларны артта калдырып, зур тормыш юлына аяк баскач, син физика, астрономия, радиофизика, хәтта нанотехнология өлкәсендә зур уңышка ирешә аласың. Физика институтының уку-укыту эшләре буенча директор урынбасары Дмитрий Таюрский сүзләренә караганда, физика фәненнән бердәм дәүләт имтиханын сайларга куркалар икән. Бу мәктәп директорлары йогынтысы да булырга мөмкин.





# Мех.+мат.=шәп белгеч!

Институтка нигез салучы гениаль математик, яхшы галим һәм оста оештыручы, 20 елга якын Казан университетында ректор вазифасын башкарган Н.И.Лобачевский исемен йөрткән Математика һәм механика институты бай тарихлы механика-математика факультеты базасында ачылды. Биредә укудан тыш вакытны да бик файдалы үткәрәләр: аспирант һәм студентлар өчен оешма эшли; үз газеталары чыга; Кече физмат, «Квант» мәктәбе мәктәп укучылары белән студентлар арасында тыгыз элемтә урнаштыра. Шулай ук эстрада миниатюралары буенча студентлар театрының уңышлары зур.



Биредә укыган студентлар универсаль, ягъни бөтен юнәлеш буенча да эшли ала, демократик, мөстәкыйль, кыска һәм аңлаешлы итеп фикерен әйтә белә торган һөнәр ияләре булып чыга. Шулай ук заман таләбенә җавап бирердәй IT-белгеч булып эшли ала. Мехмат галимнәренең Кама елгасы аша төзелгән күперне хисаплау, метрополитен өчен Казансу астындагы тоннельнең ныклыгын тикшерү, КамАЗның конструкциясен яхшырту өчен күп кенә үзгәрешләр кертүдә катнашуы институтның абруен тагын да арттыра.

# Лемма-теоремаларны үз сүзең белән!

Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты математика һәм информатика өлкәсендә Россиянең алдынгы белем бирү һәм мәгариф үзәге булып тора. Укытуга, фәнгә, сәнәгать һәм икътисад өлкәсендә санау техникасын кулланура бәйле белгечләр әзерләнә биредә. Югары квалификацияле укытучылар, яңа укыту методлары, заман техникасы ярдәмендә студентлар, ныклы теоретик белем алудан тыш, актуаль практик тәҗрибә дә алып чыга. Бу, әлбәттә, укып бетергәч, яхшы эш табарга зур мөмкинлекләр ача.


«РейтОР» бәйсез рейтинг агентлыгы хезмәт базарына бәйле уздырган масштаблы



тикшеренүдә Россиянең 23 шәһәреннән 129 югары уку йорты катнашкан иде. Казан университеты «Мәгълүмати технологияләр» юнәлеше буенча «Студентның көндәшлеккә сәләтлелеге» номинациясендә беренче лидага үтте. Бу Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институтының эш нәтиҗәсен күрсәтә.

# Геолог булыйм дисәң

Җәмгыять үсешенә бәйле булган фәнни-техник прогресс геология фәненең алга китүенә дә йогынты ясый. **Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты «Геология» юнәлеше буенча – геология; экологик геология; геохимия; геофизика; геология һәм яна торган казылма байлыкларның геохимиясе; гидрогеология һәм инженерлык геологиясе белгечлекләренә, «Кара алтын-газ хезмәте» юнәлеше буенча бакалавриат программасына** абитуриентлар кабул итә. Әлеге дисциплиналардан тыш, уку дәверендә бизнес һәм маркетинг, хокук һәм юриспруденция нигезләренә өйрәнергә була. Шулай ук булачак геологлар укыту базаларында һәм Идел елгасы, Уралда, Татарстан, Көнбатыш һәм Көнчыгыш Себер, Якутиянең геологик оешмаларында кыр һәм производство практикалары вакытында тәҗрибә туплый. Институтта халыкара хезмәттәшлеккә дә зур игътибар бирелә. Түбәндәге фәннәрдән БДИ нәтиҗәләре булу шарт: **математика; физика; рус теле.**



# Хыяллар чынга аша

Һәр кеше актив карьера үсеше булган перспективалы эш турында хыяллана. Мондый һөнәр иясе булу өчен, яхшы белем һәм махсус күнекмәләр кирәк. КФУның Мәгълүмати технологияләр һәм мәгълүмати системалар югары мәктәбе хыялларны тормышка ашыра. 2011 елда гына оешкан бүлектә хезмәт базарында ихтыяҗ зур булган «Гамәли информатика» юнәлеше буенча бакалаврлар әзерләнә. Биредә абитуриентлар математика, информатика һәм рус теленнән БДИ нәтиҗәләре буенча кабул ителә.

ТР ның Мәгълүматлаштыру һәм элемтә министрлыгы, Казан федераль университеты, төбәкнең эре IT-компания вәкилләре, шулай ук даңлыклы IBM, Microsoft, HP, Cisco, Oracle брендлары «Премиум» инновацион IT-факультет класс ачу өчен күп көч куйды. Әлеге мәктәптә белем алучы студентларга уку йортыбызның алдынгы галимнәре генә түгел, IT-компанияләрнең профессиональ белгечләре, дөньяның иң яхшы уку йортларыннан килгән укытучылар лекцияләр укый, махсус курслар үткәрә. Һәр студент индивидуальлеге белән аерыла, үз белгечлеге буенча оста.



# Милләтебезне сөючеләргә!

Алисә БИЛАЛОВА

Иҗаттан ерак кеше киләчәген филология белән бәйләми. Бу өлкәдәге бүгенге вәзгыятьне өйрәнеп, 2012 елда кабул итү шартларына беркадәр үзгәрешләр кертелгән.

**Шулай итеп, быел абитуриентларны кабул итү берничә яңа юнәлешләр буенча башкарылачак. Педагогик белем бирү юнәлеше буенча:**

- татар теле, әдәбияты һәм инглиз теле;
- татар теле, әдәбияты һәм хокук белеме;
- татар теле, әдәбияты һәм мәктәпкәчә белем бирү;
- татар теле, әдәбияты һәм башлангыч белем бирү.

**Кабул итү имтиханнары:** рус теле һәм җәмгыять белеменнән – БДИ, татар теленнән БРИ (яки университетта тест үткәреләә) тапшырырга кирәк булачак.

**Ә филология юнәлеше буенча:**

- Ватан филологиясе: татар теле һәм әдәбияты;
- гамәли филология;
- татар теле һәм әдәбияты, гарәп теле (Ислам мәдәниятен һәм тарихын тирәнтен өйрәнү);
- гамәли филология: татар теле, әдәбияты һәм мәгълүмати технологияләр дигән белгечлекләргә студентлар кабул ителә.

**! Имтиханнар - рус теле һәм рус әдәбиятыннан БДИ, татар теленнән БРИ (яки тест нәтиҗәләре).**

Татар филологиясен сайлаучыларны гаҗәеп кызыклы, мавыктыргыч тормыш көтә. Бүлекне тәмамлаган студентлар арасында талантлы язучылар, журналистлар, теле-радиотапшыруларны алып баручылар, актерлар, җәмәгать эшлеклеләре булу да шул хакта сөйли. Бүгенге көндә бүлектә **«Әллүки»** һәм **«Илһам»** әдәби-иҗат берләшмәләре яңа шартларда эшләрен дәвам итә. «Илһам» оешмасы 4 ел дәвамында мәктәп укучылары арасында Бөтенроссия «Илһамлы каләм» бәйгесен оештыра, «Әллүки»нең «Шигъри сабантуй» бәйгесендә, студентлар белән беррәттән, мәктәп балалары да көч сынаша. Бу бәйгедә катнашучылар безнең бүлекнең киләчәге икәнен аңлап эш итәбез, ди бәйгене оештыручылар.

Бирегә, нигездә, авылдан килгән балалар укый. Бүлектә белем алучы **барлык студентлар да тулай торак белән тәэмин ителгән.** Алар шәһәр үзәгендәге һәм Универсиада авылындагы заманча торакта яши.

«Бүлектә белем алып чыккан студентларның татар халкына милли тәрбия бирү, татар телен, әдәбиятын, тарихын һәм чит телләрне укыту, милли мәдәният, фән өлкәсендә нәтиҗәле эшләүләрен оештыру йөзеннән, махсус **эшкә урнаштыру комиссиясе** эшли. Бүлегебезнең киләчәге өметле булуына ышанабыз», – ди татар филологиясе бүлеге мөдире, филология фәннәре докторы Флёра Сәгыйть кызы Сәйфулина.

# Татарга тылмач кирәк...

Динара ӘХМӘТОВА

ФИЛОЛОГИЯ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫНЫҢ ТӘРҖЕМӘЧЕЛЕК ҺӘМ МӘДӘНИЯТАРА БАГЛАНЫШЛАР БҮЛЕГЕ ҖИТӘКЧЕСЕ, ФИЛОЛОГИЯ ФӘННӘРЕ ДОКТОРЫ, ПРОФЕССОР ӘЛФИЯ ШӘҮКӘТ КЫЗЫ ЮСУПОВА БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ КОРДЫК.

**– Әлфия Шәүкәтовна, бүлектә нинди юнәлешләр буенча белем алырга мөмкин? Укырга керү өчен, нинди имтиханнар тапшырырга кирәк?**

– Бүлектә гамәли филология һәм тәрҗемә; лингвистика: тәрҗемә теориясе һәм практикасы; гамәли филология: рус теле, әдәбияты һәм татар теле, әдәбияты юнәлешләрендә бакалаврлар әзерләнә. Керү имтиханнары: рус теле, рус әдәбияты, инглиз теленнән БДИ. 3 юнәлештә магистратурага кабул итәбез: лингвокультурология, лингвистика һәм тәрҗемә.

**– Яңа белгечлекләр ачылу көтеләме?**

– Яңа уку елында бакалавриат буенча чит тел буларак татар теле һәм рус теле белгечлеге кертеләчәк. Монда Кытай татарлары вәкилләрен алырга телибез. 21 Кытай татары татар һәм рус телләрен махсус курсларда өйрәнә.

**– Абитуриентлар өчен нинди кызыклы чаралар үткәрәсез?**

– Быел республика күләмендә беренче тапкыр «Татарга тылмач кирәк» дигән конкурс уздырырга уйлыйбыз. Анда 9-11 сыйныф укучылары катнаша ала. Тәрҗемәнең төрле төрләре буенча сынаулар әзерлибез. I тур Интернет аша үткәреләчәк. II турга катнашучылар институтка килеп, үз белемнәрен күрсәтәчәк. Йомгаклау турын үткәрүне Тукайның туган көненә планлаштырабыз. Җиңүчеләргә тәрҗемә төркеменә кергәндә өстенлекләр биреләчәк.

**– Һөнәр сайлауда ата-ана мөһим роль уйный. Аларга ни әйтерсез?**

– Соңгы елларда татар филологиясе белән бәйле белгечлекләрнең артык популяр булмавы сер түгел. Бу белгечлекләрне сайлаудан бала түгел, ата-ана курка. Сиңа нәрсәгә кирәк ул, әнә икътисад бүлегенә бар, ди. Әти-әниләр бала фикеренә каршы килмәсеннәр иде.



Татар филологиясен сайлаучы студентлар шушы матур бинада белем алачак



«Илһамлы каләм» конкурсыннан

Материалларны Динара ӘХМӘТОВА әзерләде



# Табигать СЕЗНЕҢ кулда!

ЭКОЛОГИЯ һӘМ ГЕОГРАФИЯ ИНСТИТУТЫ - ИН ЯШЬ ИНСТИТУТЛАРНЫН БЕРСЕ. УЛ ҮЗ ЭЧЕНӘ ТАГЫН 3 БҮЛЕКНЕ БЕРЛӘШТЕРӘ: ЭКОЛОГИЯ БҮЛЕГЕ, ГЕОГРАФИЯ һӘМ ТУРИЗМ БҮЛЕГЕ, ГЕОГРАФИК һӘМ ЭКОЛОГИК БЕЛЕМ БИРҮ БҮЛЕГЕ.



Институт **фәнни үзәкләре, лабораторияләр, практика базалары, метеорологик обсерваториясе** белән дан тота. Студентлар уку белән практиканы берьюлы алып бара. Шулай ук институт «Алабуга» ачык икътисади зона, «Татнефть» ААҖ, Универсиада корылмалары өчен зур фәнни тикшеренүләр уздыра.

Институтны тәмамлаган белгечләр **тирә-якны саклау, экологик куркынычсызлык, табигый ресурсларны рациональ куллану буенча туган проблемаларны, экологик мониторинг, менеджмент, экосистемаларны сәламәтләндерү** методлары өлкәсендәге сорауларны профессиональ рәвештә хәл итә.

Гидрометеорология юнәлеше буенча белем алып чыккан студентлар башкарган хезмәт һәркем өчен һәркөнне кирәк булачак. Алар атмосфераның составын, төзелешен, физика һәм динамикасын, мәгълүмати һәм космик технологияләр ярдәмендә һава торышын өйрәнә.

Туризм һәм кунакханә эше белгечлекләрен үзләштергән бакалаврлар проектлаштыру институты һәм компанияләрендә, фәнни-тикшеренү оешмаларында, туристлык агентлыкларында, кунакханә, ресторан комплексларында, музей һәм мәгариф учреждениеләрендә уңышка ирешә ала.

Педагогик белем бирү юнәлешен тәмамлаган студентлар ике куянның койрыгын тотачак. Көндезге бүлектә берьюлы ике белгечлек алырга була: **география+инглиз теле, география+биология, экология+инглиз теле.**

Әгәр сине табигать кызыксындырса, аның белән бәйле проблемалар борчыса, Җир-анабызны саклауга үз өлешеңне кертәсең килсә, Экология һәм география институтына укырга кил. Россиянең генә түгел, чит илләрнең алдынгы уку йортларында стажировка үтү, хезмәт базарында алдынгы урыннардагы һөнәрләр, иң матур урыннарда гына җәйге практика һәм романтик экспедицияләр, әлбәттә инде, онытылмаслык студент еллары көтә.

# Фармаколог фармацевт түгел!

Ил күләмендә алдынгы юнәлешләрне булдыру максатыннан, Казан федераль университетында яңа проектлар, идеяләр тормышка ашырыла. Медицина һәм биологик технологияләр аеруча алга киткән өлкәләрдән санала. Биология һәм туфракны өйрәнү факультетында фундаменталь һәм клиник фармакология кафедрасы ачылды. Фармакология белән фармацевтиканы бутарга ярамый. Фармакология кеше һәм хайваннар организмына даруларның ничек тәэсир итүен өйрәнә. Кафедраның төп максаты – укыту, тикшеренү һәм эксперт мәйданы булдыру. Шулай ук «ФАРМА 2020» программасын тормышка ашыру кысаларында фармацевтика буенча фәнни-белем бирү үзәге ачылды. Биредә инновацион дарулар һәм субстанцияләр эшләп чыгару белән шөгыльләнәләр. Бу процесска химия, биология, медицина һәм фармтехнология буенча белгечләр җәлеп ителде.

Гомумән, КФУда фармацевтика юнәлешен җәелдерү зур тизлек белән бара.

2011 елдан биолог һәм химикларны «Биология» юнәлеше буенча «Фармакология»гә магистратурага кабул итәләр. Фармакология профиле буенча әзерләнгән магистрлар төрле фармацевтик оешмаларда, тикшеренү лабораторияләрендә, биотехнологик компанияләрдә, югары һәм урта уку йортларында эшли ала.





# Кытайча да яхшы бел!

Конфуций – Кытай мәдәниятенең якты вәкиле. 70 еллык тарихы булган Хунань педагогия университеты дөнья күләмендә шул исемдәге XXI гасырның иң яхшы Кытай институтларын ачуны максат итеп куя. Әлеге университет Казан дәүләт университеты белән 1989 елдан бирле хезмәттәшлек итә. Бүген әлеге хезмәттәшлек яңа баскычка күтәрелде. КФУ базасында 2007 елдан бирле Конфуций институты эшли.

Биредә һәркем үз максатларыннан һәм мөмкинлекләреннән чыгып, теләгән курсларны сайлый ала. Бүгенге заманда кытай теле фикерләү сәләтен үстерергә генә түгел, ә язмышын бизнес белән бәйләүчеләр өчен аеруча кирәк. Конфуций институты кытай теле һәм мәдәнияте буенча башлангыч, урта һәм югары мәктәпләр өчен укытучылар әзерли, иҗади һәм фәнни конкурслар, чаралар уздыра, төрле өлкәдә эшләүчеләр өчен курслар үткәрә. Шулай ук биредә укучылар кытай фильмнары һәм телевизион программалар карый ала.

Телне өйрәнә башлаучылар өчен стандарт курста сөйләшү, уку һәм ишетеп аңлау күнекмәләре тәкъдим ителә. Кытай телен өйрәнү тәҗрибәсе булганнарга индивидуаль дәресләр яисә эшлекле кытай теле курсларын сайларга мөмкин. Җәйге курслар кытай телен тиз арада өйрәнергә ярдәм итә. Биредә шулай ук халыкара HSK тестын (кытай телен нинди дәрәҗәдә белүне барлау) тапшыру өчен дә әзерлиләр.

Иң кызыклы бүлекләрнең тагын берсе – каллиграфия серләренә, ягъни кытай иероглифларын язарга өйрәтү. Кытайда каллиграфияне яхшы белү белемле булуны һәм югары сәнгатькә ия икәнлекне күрсәтә.

Димәк, кытайча сөйләшергә һәм матур итеп язарга теләсәң, сиңа, дустым, Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институтына ашыгырга кирәк!



● Кытай Халык Республикасы рәисе Ху Цзинь Тао визиты. Март, 2007 ел.

Материалларны Динара ӘХМӘТОВА әзерләде

# Журналистлар – үз өйләрендә!

ЖУРНАЛИСТИКА БУЕНЧА ТАТАРСТАНДА ЮГАРЫ БЕЛЕМЛЕ БЕЛГЕЧЛӘР ӘЗЕРЛИ ТОРГАН БЕРДӘНБЕР ҮЗӘК – ЖУРНАЛИСТИКА ҺӘМ СОЦИОЛОГИЯ ФАКУЛЬТЕТЫ. ФАКУЛЬТЕТ УКЫТУЧЫЛАРЫ ЯР ЧАЛЛЫ ФИЛИАЛЫНДА ДА ДӘРЕСЛӘР АЛЫП БАРА. СТУДЕНТЛАРНЫН 75-80% ҮЗ БЕЛГЕЧЛЕГЕ БУЕНЧА ЭШКӘ УРНАША. ФАКУЛЬТЕТНЫ НИНДИ ҮЗГӘРЕШЛӘР КӨТӘ? АНЫҢ БҮГЕНГЕСЕ ҺӘМ ҮТКӘНЕ ТУРЫНДА БЕЗ ФАКУЛЬТЕТ ДЕКАНЫ, ФИЛОЛОГИЯ ФӘННӘРЕ ДОКТОРЫ ВАСИЛ ЗАҺИТ УЛЫ ГАРИФУЛЛИННАН БЕЛДЕК.



**– Васил абый, бу семестрны яңа урында башлап җибәрдегез. Кәефләрегез ничек?**

– Аллага шөкер, бар да яхшы. Бүген берникадәр яңа шартларда эшлибез. КФУ салган юнәлеш буенча үзебезнең үсеш программасын булдырдык. Аны тормышка ашыру өчен, аерым бина бирделәр. Ул өч катлы, бик зур, үз өебез булу студентларга да ошый. Төрле биналар буенча йөгереп йөрисе юк. Бу җиһазланыш өчен бик яхшы. Университет телеүзәге белән бергә монда өйрәнчек телевизион студия урнаштырабыз. Иң алдынгы студияләрдә генә эшли торган җиһазларны Мәскәү белгечләре куячак. Материалны эшкәртү, ягъни монтажлау аппаратлары да булачак. Интернет челтәрендә трансляцияләнә торган көчле заманча телевизион мәйдан булдыру юнәлешендә зур эш алып барыла. Факультетның һәр студенты 1 сентябрьдән үз тапшыруларын эфирга әзерли һәм чыгара алачак. Фотожурналистика студиясен җиһазландыра башладык. Компьютер класслары ачтык. Өйрәнчек газета редакциясе бар. Кече курс студентлары, төркемнәргә берләшеп, семестрга бер тапкыр үзләренең газетасын чыгара.

**– Уку-укыту эшчәнлеге ничек бара? Нинди яңалыклар бар?**

– Без дә ике баскычлы укытуга күчтек. 2011 елда беренче тапкыр бакалавриатка кабул иттек. Бакалавр-студентларның эш күләме зур, программалары шактый тыгыз.

**– Социология бүлегендә нинди үзгәрешләр бар?**

– Шулай ук бакалавриатка кабул итәбез. Магистратура буенча яңа юнәлешләр ачтык. Бездә мәдәният социологиясе, сәяси проблематика буенча белгечләр юк. Бу Татарстан өчен аеруча кирәк. Телевидение буенча да магистратура ачарга уйлыйбыз. Бирегә башка белгечлекне тәмамлаганнар да килә ала. Журналистика юнәлешенең рус бүлегенә керү өчен, чит телдән имтиханны бетердек, чөнки махсус мәктәптә укымаган укучылар бу БДИны сайларга курка. Халыкара журналистика бүлеге өчен кирәк, әлбәттә. Журналист чит тел белергә тиеш, ләкин укырга кергәндә, ул фәннән имтихан тапшыруны мәҗбүри куюдөрес түгел.

**– Татар төркемнәренең киләчәге бармы? Нинди имтиханнар нәтиҗәсендә кабул итәсез?**


– Соңгы елларда абитуриентлар саны кимеде. Моны без рус әдәбиятыннан БДИ кертелү белән аңлатабыз. Аеруча татар теле һәм әдәбиятыннан, тарихтан белемнәрнең яхшы булуы мөһим. Шуның өчен дә без – иҗади имтиханны саклап калган бердәнбер факультет. Ул безгә студентның иҗади сәләтен, милли тел, әдәбият, тарих, сәнгать буенча элементар белемен барларга, әлеге һөнәргә мөнәсәбәтен аңларга ярдәм итә.

**– Укырга кергәндә, кемнәргә өстенлек бирелә?**

– Бездә бер генә юнәлеш буенча өстенлек бар. Ул - «Алтын каләм» фестивале. Гран-при яулаган конкурсантларга иң югары балл куела. БДИны уңай тапшырган булса, факультетка кабул ителә. Журналист булырга теләгән укучыларга фестивальдә активрак катнашырга киңәш итәм. Безгә укырга керүчеләргә, яшьләр теле белән әйтсәк, креатив булырга кирәк. Иҗади публикацияләре булса, бик яхшы. Кешегә яхшы мөнәсәбәттә, аралашучан, энергияле, максатчан, яхшы мәгънәдә үҗәт булу мөһим. Әлбәттә, татар халкына хас әдәплелек, итәгатьлелек кебек сыйфатларга да ия булсыннар иде.



• Студентлар - журналистлар тапшыру әзерли



# Кем мин?

**Белгеч** – студент тарафыннан махсус укыту программасы үзләштерелгән квалификация. Россиядә белгечләр 5 ел әзерләнә. Квалификация Дәүләт аттестацион комиссиясендә яклаган диплом проекты яки диплом эше нәтиҗәләренә карап бирелә һәм магистратура яисә аспирантурага керү мөмкинлеге бирә. Кайбер медицина белгечлекләре алып чыккан (дәвалау эше, фармация, медик-профилактик эш, педиатрия, стоматология) студентлар, дәүләт, муниципаль оешмаларында эшләү өчен, интернатураны тәмамларга тиеш. Киләчәктә «белгеч» дигән квалификацион дәрәҗә юкка чыгачак, чөнки югары белем алуга бәйле законда яна дәрәҗәләр барлыкка килде.

**Бакалавр** – югары белемнен укыту программаларын үзләштергән кешеләргә бирелә торган академик дәрәҗә яки квалификация. Болонья процессында катнашучы илләр өчен тәмамланган югары һөнәри белем буларак санала. Бакалавр дипломы югары белем таләп ителә торган урынга эшкә урнашканда кулланыла ала һәм магистратурада укуны дәвам иттерү мөмкинлеге бирә. Россиядә бу дәрәҗә 1996 елда кертелде. Белем алу срогы 4 елдан да ким түгел.

**Магистр** – студентка магистратураны тәмамлагач бирелә торган академик дәрәҗә яки квалификация. Магистратура – бакалавриаттан соң килә торган югары һөнәри белем баскычы. Ул аерым бер һөнәри юнәлеш буенча белгечлекне тирәнтен өйрәнергә ярдәм итә. Күп кенә алдынгы илләрдә магистр дипломы иң яхшы дипломнардан санала, бер уку йортыннан икенчесенә күчү мөмкинлеге бирә. Магистр программасын үзләштерү вакыты (көндезге бүлектә) – 2 ел. Магистрга, диссертациясен яклагач, аспирантурага керү мөмкинлеге бирелә.

2010 елның 31 декабреннән башлап бакалавр һәм магистр Россия югары уку йортлары өчен төп квалификация булып тора.

**Аспирант** – аспирантурада укып, билгеле бер өлкә буенча фән белән шөгыльләнүче югары белемле студент. 3 ел дәвамында (көндезге бүлектә) махсус программаны үзләштергәннән соң, «аспирант» дәрәҗәсе бирелә. Сайлап алынган юнәлеш буенча ул фәнни тикшеренү эше алып бара. Фәнни хезмәтен Югары аттестацион комиссия раслаган советта яклаганнан соң, ана фән кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә бирелә.


# Һәрчак элемтәдә!

Зилә ФӘСХИЕВА

УНИВЕРСИТЕТЫБЫЗДА БУЛАЧАК ЖУРНАЛИСТЛАР ГЫНА ТҮГЕЛ, ГАДИ СТУДЕНТЛАР ДА КАЛӘМНӘРЕН ЧАРЛЫЙ, ҮЗЛӘРЕН МИКРОФОН КАРШЫНДА СЫНАП КАРЫЙ АЛА. ҮЗЕГЕЗНЕ БОРЧЫГАН МӘСЬӘЛӘЛӘРНЕ, УЙ-ТЕЛӘКЛӘР, КИЧЕРЕШЛӘРЕГЕЗНЕ БАШКАЛАР БЕЛӘН ДӘ УРТАКЛАШАСЫГЫЗ КИЛСӘ, РУС ТЕЛЕНДӘ ЧЫГА ТОРГАН «КАЗАНСКИЙ УНИВЕРСИТЕТ» ҺӘМ ТАТАР ТЕЛЕНДӘ – «DARELFӨNYN» ГАЗЕТАЛАРЫНА, МАТБУГАТ ҮЗӘГЕНӘ ЯКИ «UNIVER TV»ТЕЛЕВИДЕНИЕСЕНӘ МӨРӘҖӘГАТЬ ИТӘ АЛАСЫЗ.

## Университетның рәсми сайты

Әгәр сезгә тиз арада гына университет белән бәйле телефон номеры я булмаса e-mail кирәк, бездә үтәчәк вакыйгалар белән кызыксынасыз икән, Интернеттан portal.kpfu.ru адресын җыегыз. Биредә сез иң соңгы һәм gөрес яналыклар, хәбәрләр белән таныша аласыз. Вакытыгызның аз гына өлешен әлеге сайтка багышласагыз да, КФУ турында бик күп мәгълүматлардан хәбәрдар булырсыз, университет тормышының үзәгендә кайнарсыз. portal.kpfu.ru



## КФУның Матбугат үзәге

Матбугат конференциясе, пресс-кит, медиа-план... Бу сүзләр күпләргә, бәлки, теория аша гына таныштыр, ә матбугат үзәгендә исә сез алар белән гамәлдә таныша аласыз. Сезгә студентларның PR-агентлык эшчәнлегендә катнашырга тулы мөмкинлекләр бар. Матбугат үзәге хезмәткәрләре шәһәр, республика газеталары битләренә, телевизор экраннары, Интернет челтәрләре аша университет абруен күтәрү юнәлешендә эшли, киң җәмәгатьчелек белән элемтәләрне җайга сала, PR-акцияләр оештыра. Биредә мөмкинлекегезне сынап карарга була. Мәкалә, пресс-релизлар язарга өйрәнәсегез, эшлекле сөйләшү, әңгәмә кору технологияләренең асылына төшенәсегез килсә, матбугат үзәге нәкъ менә сезнең өчен. portal.kpfu.ru

## «UNIVER TV»ТЕЛЕВИДЕНИЕСЕ




Атнага дүрт тапкыр «Univer news» мәгълүмати программасы эфирга чыга. Әлеге телепрограмма аша сез кафедра, бүлекләрдә, факультет, институтларда һәм, гомумән, университетта ниләр булганын, студентлар, укытучы, хезмәткәрләребезнең ничек яшәве белән таныша аласыз. Тапшырулар һәм барлык язмалар ksu.ru/univer tv/video сайтына урнаштырылган. Телевизион тапшырулар эшләүдә син дә катнаша аласың! universmotri.ru

## КФУның «Казанский университет» газетасы

Әлеге газетаны, үз мәгънәсендә, университетның елъязмасы дияргә була. Газетага шулай ук теләгән һәр кеше яза, фикерен белдерә, университет тарихын теркәүгә үз өлешен кертә ала. Газета белән Интернет челтәрендә ku.ksu.ru адресы буенча кереп танышырга да мөмкин. Әгәр университет тарихын язышуда үзегезнең яна алымнарыгыз, теләгегез бар икән, редакция ишекләре сезнең өчен һәрвакыт ачык. Университетыбыз газетасын бергә гамәлгә ашырыйк! ku.kpfu.ru

## Татар яшьләренең «DARELFӨNYN» газетасы

«DARELFӨNYN» – университет тормышын, галим-мөгаллимнәр, студентларның уй-фикерләрен туган татар телебездә чагылдырган көзге ул. Яше буенча университет күләмендә барысыннан да калышса да, мәгълүмат җәһәтлеге һәм татар телле укучыларны берләштерү ягыннан алда бара. Газета битләрендә сезне мавыктыргыч язмалар көтә. Интернет челтәрендә дә яна саннар белән таныша аласыз. ksu.ru/df/index.php сылтамасы буенча керү – «DARELFӨNYN»гә эләгү дигән сүз. Редакция вәкилләре сәлатле, язу-сызуга һәвәс яшьләрне бик теләп һәм яратып үз сафларына алырга әзер!

dksu.ru/df/index.php

# Ашыйбыз: кайда, ничек, күпме?

Алисә БИЛАЛОВА

Рәдифә ШӘФЫЙКОВА, КФУның Матбугат үзәге хезмәткәре: «Минем эш урыным КФУның төп бинасында урнашкан. Күршебездә генә «Лоза» кафесы бар, шунда керәбез. Ләкин бу – «дорогое удовольствие». Акча ягыннан студентның кесәсенә сукмый торганы – Физика институты корпусының ашханәсе. Анда тәмле, уңайлы һәм шул ук вакытта арзан да».

Лилия ШАКИРОВА, Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты студенты: «Буфет, ашханәләр ягыннан зарланмыйбыз. Кирәк чакта тамак ялгарга 2 нче уку бинасының беренче катында урнашкан буфетыбыз бар. Биредә камыр ризыклары, пицца, кайнар кәһвә яки чәй, теләгән кешегә төрле шоколад һәм соклар сатыла. Икенче катта ашханә эшли. Биредә инде чын мәгънәсендә тамак туйдырырга була. Менюда беренче, икенче ашлар, салатлар бик күп. Бәяләре дә студент кесәсенә ярарлык».

Илгиз МӨХӘММӘТОВ, Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты студенты: «Үзебезнең институтта – Сул Болак урамы, 44 йорт адресы буенча урнашкан бинада буфет бар. Әлбәттә, бу буфетта ныклап туклану мөмкин түгел, бигрәк тә безнең кебек хәрәкәттә булган кешеләр өчен. Шулай да ашыкканда тамак ялгарга була. Бинаның үзәктә урнашуы бик әйбәт, тирә-ягыбызда буфет-кафеләр бик күп. Ешрак «Апельсин» дигән кафега керәбез. Анда 50-70 сумга әйбәт кенә ашап чыгарга мөмкин».

Алсу ХАФИЗОВА, Филология һәм сәнгать институты студенты: «Мин Татарстан урамында урнашкан бинада укыйм. Аскы катта «Трали-вали» кафесы эшли. Биредә тәмләп ашау 90 сум тирәсенә чыга, кыйбатрак инде, әлбәттә. Хәләл ризык ашарга теләсән, университет тирәсендә урнашкан кафеларга барырга була. Якын урыннарда алар күп һәм аларда бик яхшы хезмәт күрсәтәләр».

Рәдиф ӘХМӘДИЕВ, Тарих институты студенты: «Без Карл Маркс урамы, 74 йортта урнашкан бинада укыйбыз. Биредә кечкенә генә буфет бар, әз-мәз тамак ялгарга була, тик әллә ни ассортимент юк. Бәяләре без – студентларның кесәсенә ярарлык, өйгә кайтканчы тамак ялгарлык булгач, зарланмыйбыз».

Гүзәл СӘЕТОВА, Икътисад һәм финанс институты студенты: «Безнең бинада (элеккеге КДФИИ) инде җирдә ашап алырга мөмкин. Бай менюлы кафе да, ашханә дә бар. Кафеда 180-200 сумга аш, икенче аш алырга, чәй эчәргә була. Шулай ук каппучино, коктейль, суши-ролл яратучылар өчен дә ассортимент зур. Ашханәдә шул ук меню өчен 100-130 сум түләргә кирәк. Биредә 30 сумга комплекслы көндезге аш (икенче аш һәм чәй) та тәкъдим итәләр».



Университетның Физика институты корпусындагы ашханәсе

# Монда хикмәт, мәгърифәт...


Материалларны Алисә БИЛАЛОВА әзерләде

«Укырга! Укырга! Укырга», – дигәнме әле Ленин бабабыз?! Мәктәптәге 11 елны ничек бетерергә белми йөрисең, тагын 4-5 ел университет килеп өстәлә. Чыгарылыш сыйныф укучыларының башында хәзер шундый уйлар чуаладыр. Студент тормышын кабул итү имтиханнары, озын-озак лекцияләр, йокысыз төннәр, зачет-имтиханнар дип кенә күз алдына китерәсең икән, кадерле абитуриент, син бик нык ялгышасың. Монда күңелсезләнеп утырырга, буш вакыт күплектән зарланырга өлгереп тә булмый. Укудан, дәресләрдән бушаган арада, кемдер спорт, бию залларына ашыга, кемнедер сәхнә, музыка класслары көтә...

Бездә бер генә бәйрәм, истәлекле дата да, студентлар күзеннән читтә калып, эзсез үтми. Ә инде синең актив студент булып, әлеге кичәләрнең үзәгендә кайныйсың килә икән, бездә эшләп килә торган иҗади үзәкләр, түгәрәкләр нәкъ менә синең өчен. Алдагы сүзем шулар турында, игътибар белән укы! Кемне җыр дөньясы үзенә тартып тора, аларны КФУда **«Ирбис», «Хәят», «Сәлам», «Ал Зәйнәбем», «IRENE Studio», «Surrise» вокаль ансамбльләре** көтә. Биюдән башка тормышларын күз алдына китерә алмаганнарга исә **«Калликория» шоу-балетын, «Action Stayle» брейк-данс бию проектын, «Тылсым», «Каз канаты», «Нурани», «Шторм», «Belly Dance», «Сакура», «Dance Lunch», «Сказка», «Flash», «Шоколад», «Аффекты», «Studance»** кебек бию түгәрәкләрен тәкъдим итәбез. Үзенең коллективы, биюләре белән дөньякүләм танылу алган, ТР атказанган артисты, **«Казан» бию ансамбле** җитәкчесе Чулпан Закированың бездә эшләп килә торган шундый ук түгәрәге белән дә горурлана алабыз.
Әлбәттә, бер генә чараны да уенкөлке, юмордан башка күз алдына китереп булмый. Университетыбыз нинди генә җитди уку йорты булмасын, анда да шаяруларның үз урыны бар. Юмордан башка яши алмыйсыз икән, сезне **КВН мәктәбе, «Параллельность» пластика театры, «ЭОС» сәнгать үзәге** көтә.
Яшь театр сөючеләребез исә үзләрен Россиянең атказанган, Татарстанның халык артисты Марсель Җаббаров җитәкчелегендәге **«Мизгел» яшьләр театрында** сынап карый алалар.
Яшь каләм тибрәтүчеләребезне татар филологиясе бүлеге базасында күп еллардан бирле эшләп килгән **«Илһам», «Әллүки»** әдәби-иҗат берләшмәләре сөендерә. Алабуга, Чаллы, Яшел Үзәндә урнашкан филиалларыбызда да студентлар, төрле җыр, бию, шигырь түгәрәкләренә йөреп, иҗат, сәнгать дөньясында кайнап яши.
Хөрмәтле абитуриент! **Уку белән беррәттән, иҗатта да кайныйсың килә икән, безнең данлыклы университетыбыз** һәм аларда эшләп килә торган йөзләгән иҗат үзәге сине көтә. Киләчәгеңне сайлаганда ялгышма һәм соңга кала күрмә!



«Мизгел» театрында - премьера





«Студентлар язы» фестиваленнән…




КВН командаларыбызның берсе

N.B. Үзен киләчәктә сәнгать белән бәйлисе килгән кешегә бездә зур мөмкинлекләр бар. **Язучы, шагыйрь, җырчы, биюче, рәссам** яисә **дизайнер** буласыгыз килсә, Филология һәм сәнгать институтында хыялларыгызны чынга ашыра аласыз. Бай тарихы булган бүлекләребезне тәмамлаган белгечләр арасында зур уңышларга ирешкән фән докторлары, профессор һәм академиклар, язучылар, РФ һәм ТР ның халык һәм атказанган артистлары, танылган шәхесләр бик күп. Институтны тәмамлаучылар әдәбият һәм сәнгатебезгә хезмәт итәләр. Алар музыка, хореография, сынлы сәнгать, дизайн һәм компьютер графикасы юнәлешендә эшли ала. Сайтның адресы: ***kpfu.ru/main_page?p_sub=222***



«Мизгел» артистлары Илназ Баһ һәм Ләйсән Шәяхмәтова

# Бай мирас - заманча белем



Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханә

Булачак студентларыбызны китапханәләр белән таныштырмасак, дөрес булмас, мөгаен. «Хәзерге заманда нинди китап уку инде ул», – дип, кул селтәргә ашыкмагыз. Университетта уку дәверендә курс, диплом эшләре язганда, Интернетның гына түгел, аларның да әһәмияте бик зур.
Язманы инде 200 елдан артык тарихы булган Казан федераль университетының **Н.И.Лобачевский исемендәге фәнни китапханәсеннән** башлау кирәктер. Ул чын мәгънәсендә Китап сарае. Фондларының зурлыгы, байлыгы белән илебездә, беренче унлыкка кереп, университетлар арасында III урында саналса, кульязмалар һәм китаплар җыелмасының борынгылыгы, байлыгы белән бары берничә урынга гына калыша. Фәнни китапханәнең фондларында эшләү өчен, бөтен Россиядән генә түгел, хәтта чит илләрдән дә киләләр. Бүгенге көндә аның **ун функциональ бүлеге, факультет һәм тулай торакларда 12 уку залы, 4 абонементы, 3 компьютер классы, фәнни-библиографик, кульъязмалар һәм сирәк китаплар бүлеге бар.** Аларда 4 млн 920 меңнән артык китап саклана. Бирелә елына 600 меңнән өстә укучы белем эсти. Китапханәдә электрон ресурслар белән эш итү өчен дә барлык уңайлыклар тудырылган. Шулай ук укучыларга электрон каталог тәкъдим ителә, Интернет челтәрендә дәреслек, энциклопедия, сүзлекләр һәм һәр фән буенча белешмәләрдән файдаланырга була. Татарстан Республикасы Милли китапханәсенең үзәктә, безнең күп кенә уку биналарыбызга якын урнашуы да уңайлы һәм җайлы. **Татарстан Республикасы Милли китапханәсендә,** укучыларны аеруча әһәмиятле һәм уникаль басмалардан файдалану мөмкинлеге белән тәэмин итү максатыннан, электрон басмалар фондын туплау эше алып барыла. Электрон коллекция 2002 елдан башлап формалаша. Бу эш 2004 елдан Россия гуманитар-фәнни фондының финанс ярдәме белән башкарыла.

Димәк, университетыбызның кайсы гына институт-факультетын, бүлеген сайласагыз да, сез аларның һәркайсында бай китапханәдән (абонемент һәм электрон китапханә, уку залы һ.б.) файдалана аласыз.


# Спорт сөючеләр өчен

Динара ӘХМӘТОВА

**Казан федераль университетында сәламәт яшәү рәвешенә, спорт белән шөгыльләнүгә зур игътибар бирелә. Моның өчен биредә бөтен мөмкинлекләр дә тудырылган. Укудан буш вакытны заманча тренажёрлар белән җиһазландырылган залларда шөгыльләнеп, физик халәтеңне ныгытырга мөмкин.**

## «Уникс» спорткомплексы

(Нужин ур., 2, тел.: 238-45-79, 292-70-06)




Биредә физик тәрбия һәм сәламәтләндерү буенча өстәмә хезмәтләр күрсәтелә. Аэробика, бодифлекс, йога, пилатес, шейпинг, бию класслары, кыяга менү, тай-бо, тренажёр залларында иң яхшы инструкторлар яңа программалар тәкъдим итә. Чиста чишенү бүлмәләре, душ, сауна, унай гәресләр тәртибе – һәммәсе спорт сөючеләр өчен. Моннан тыш, медицина фитнес-лабораториясендә компьютерлашкан тест ярдәмендә сәламәтлекне тикшерергә һәм аерым киңәшләр алырга мөмкин. КФУ хезмәткәрләре, студентлар (һинди вузда һәм һинди бүлектә укуына карамастан), укучылар һәм лаеклы ялдагылар өчен 25% ташлама каралган.

## «Бустан» универсаль спорткомплексы

(В.Кулагин ур., 8а, тел.: 221-04-02, 237-64-21)



Комплекс гомуми мәйданы 3499 һәм 6196 кв.м зурлыкта булган ике бинадан тора. Биредә универсаль спорт залы, йөзү бассейны, тренажёр залы, шулай ук медицина һәм административ блоклар бар. 2013 елга узачак Җәйге студентлар Универсиадасында спорткомплекста волейбол буенча кайбер ярышлар үткәрелер дип көтелә. Йөзүчеләр өчен тренировкалар үткәреләчәк. КФУ хезмәткәрләренә тренажёр залында шөгыльләнү



өчен 50% ташлама бирелә. Шулай ук хезмәткәрләр якшәмбе көнне көндезге өчтән дүрткә кадәр бассейнда бушлай йөзә ала.

## «Буревестник» спорткомплексы

(Универсиада авылы, 33 (Җиңү проспекты), тел.: 221-09-25)



«Буревестник» спорткомплексы Универсиада авылында урнашкан. «Оргсинтез»дан соң зурлыгы буенча икенче урында торган «Буревестник» йөзү бассейнының озынлыгы 50 метр. Биредә иртәнге 6.15 тән кичке 10 га кадәр шөгыльләнергә мөмкин. Бәяләр чагыштырмача кыйммәт түгел. Спорткомплекста йөзәргә өйрәнү, уен һәм тренажер заллары да бар. 24х12 метр зурлыктагы йөзәргә өйрәнү залында суда үзеңне тоту техникасының асылына төшенергә, төрле күнегүләр ясарга ярдәм итәләр. Тренажер залы да заманча таләпләргә туры китереп җиһазландырылган. 36х24 зурлыгындагы уен залы исә универсаль. Биредә волейбол һәм баскетбол уйнарга мөмкин. Тагын шунысы мөһим: «Буревестник» спорткомплексы Универсиада авылында яшәүче студентларның янәшәсендә генә. Каядыр барып, йөзү, спортның башка төрләре белән шөгыльләнү өчен, урын эзлисе юк.

## «Мәскәү» спорткомплексы

(Мәскәү ур., 45а, тел.: 236-76-40)



Корылманың гомуми мәйданы 5148 кв.м тәшкил итә. Биредә спорт залы, тренажёр, көрәш белән шөгыльләнү заллары, аэробика, авыр атлетика, шулай ук медицина һәм административ бүлмәләр бар. Җәйге Универсиада вакытында волейбол буенча күнегүләр уздырылачак. КФУ хезмәткәрләре өчен тренажёр залына 50% ташлама каралган.




● Универсиадаы каршылап

## «Теннис академиясе»

(Оренбург тракты, 101, тел.: 221-67-81)



«Теннис академиясе» – Казан шәһәре халкы өчен ишекләрен ачкан Универсиада объектларының берсе. Мәйданы 8,5 га булган комплекс эчендә йөри торган трибуналы 8 ябык һәм 18 ачык теннис корты бар. Төп ачык кортта уен барышын – 3 мең, ә кече трибунада 1 мең тамашачы күзәтә ала. 19,5 кв.км мәйдан биләп тора торган академиядә күнегүләр өчен 8 корт урнаштырылган. Уен барышын 3200 кеше – төп аренада, 400е икенчесендә күзәтә ала. Биредә ел саен «Казан Кремле Кубогы»на ярышлар уздырыла. 2013 елда Бөтендөнья Җәйге студентлар Универсиадасы вакытында теннис һәм бадминтон буенча ярышлар үтәчәк.




● КФУ егетләре



● Йөрәк эшчәнлеген шулай тикшерәбез

**N.B.**

**Физик тәрбия һәм терәкләндерү медицинасы институты** ишекләре спорт сөючеләр өчен һәрвакыт ачык. Институтны тәмамлаган студентлар **физик тәрбия һәм тормыш иминлеге укытучысы, спорт белгече** булып чыга.

Бинада гомуми һәм индивидуаль дәресләр өчен аудиторияләр бар. Практиканы студентлар урта гомуми белем бирү учреждениеләрендә, балалар һәм яшьләр өчен урта мәктәпләрдә, «Динамо», «Рубин», «Зенит» кебек спорт оешмаларында үтә. I һәм II курс студентлары өчен «Яльчик» укыту-сәламәтләндерү үзәгендә дәресләр уздырыла.

Студент елларында ук зур уңәр яулап, ил күләмендә танылу турында кем генә хыялланмый икән?! КФУда спортка, сәламәт яшәү рәвешенә игътибар аеруча зур. Ә Физик тәрбия һәм терәкләндерү медицинасы институтын тәмамлаучыларның күбесе, диплом алганда, **Татарстан, Россия,** хәтта **дөнья чемпионы** дәрәҗәсенә ия була.

## Схема 1.
## КФУ филиаллары




### Яр Чаллы филиалы

Яр Чаллы ш., Сөембикә пр., 10а
fksu.ru

**Факультетлар:**

- Юридик
- Икътисад
- Гамәли математика һәм мәгълүмати технологияләр
- Чит телләр
- Филология һәм журналистика

UNIVERSMOTRI.RU
kpfu.ru/main_page?p_cid=4968&p_sub=8773

### Яшел Үзән филиалы

Яшел Үзән ш., С.Сәйдәшев ур., 4
green.ksu.ru

**Факультетлар:**

- Физика-математика
- Гуманитар

### Алабуга филиалы

Алабуга ш., Казан ур., 89
egpu.ru

**Факультетлар:**

- Биология
- Технология-инженерия
- Чит телләр
- Тарих һәм юриспруденция
- Психология һәм педагогика
- Рус филологиясе һәм журналистика
- Татар һәм чагыштырма филология
- Физик культура
- Икътисад һәм идарә
- Физика-математика

*Тиздән КФУ составына тагын бер вуз кушылачак. Ул - Тольяттиның **В.Н.Татищев** исемендәге Волжск университеты.*

UNIVERSMOTRI.RU
kpfu.ru/main_page?p_cid=5155&p_sub=8773

## Схема 2.
## Казан шәһәрендә КФУ төп биналарының урнашу тәртибе

**КФУ ның төп бинасы,** *Кремль ур., 18*
**Биология һәм туфракны өйрәнү факультеты, Юридик факультет**

**А.М.Бутлеров исемендәге Химия институты,** *Лобачевский ур., 1/29*

**II корпус** *Кремль ур., 35*
**Экология һәм география институты, Н.И.Лобачевский исемендәге Математика һәм механика институты,**

**Хисаплау математикасы һәм мәгълүмати технологияләр институты, Мәгълүмати системалар һәм технологияләр югары мәктәбе** *Проф.Нужин ур., 1/37*

**УНИКС мәдәни-спорт комплексы** *Проф.Нужин ур., 2*

**Тарих институты** *К.Маркс ур., 74*

**Журналистика һәм социология факультеты** *Товарищеская ур., 5*

**Геология һәм кара алтын-газ технологияләре институты,** *Кремль ур., 4/5*

**Идарә итү һәм территориаль үсеш институты,** *Кремль ур., 6/20*

**Физика институты** *Кремль ур., 16*

**Физик тәрбия һәм тернәкләндерү медицинасы институты,** *Сул Болак ур., 44*

**Педагогика һәм психология институты,** *Межлаук ур., 1*

**Филология һәм сәнгать институты,** *Межлаук ур., 3/45*

**«Мәскәү» спорткомплексы,** *Мәскәү ур., 49*

**Көнчыгышны өйрәнү һәм халыкара багланышлар институты,** *Пушкин ур., 1/55*

**Фәлсәфә факультеты,** *Пушкин ур., 1/55*

**Филология һәм сәнгать институты,** *Татарстан ур., 2*

**Икътисад һәм финанс институты,** *Бутлеров ур., 4*

**«Бустан» спорткомплексы, «Бустан» бассейны,** *Кулагин ур., 8а*

**Универсиада авылы, «Буревестник» бассейны, Теннис академиясе**




Универсиада авылына бару схемасы (47 нче номерлы маршрут)

Казан федераль университеты
«DARELFӨNYN» газетасының махсус чыгарылышы

Мөхәррир – Рамил Гомәр улы Ханнанов
Иҗат коллективы: С.М.Трофимова, Д.Р.Әхмәтова, А.И.Билалова, З.Ф.Фәсхиева
Биткә салу һәм дизайн буенча белгеч – Г.З.Камалиева
Фотохәбәрчеләр: А.Галимуллина, Ә.Фазлыйәхмәтов, С.Тябин, Э.Ибраһимова, Р.Газизов, Р.Гыйниятуллин, Р.Кирилова
Газета бушлай таратыла
Тираж 3000

Газетаны гамәлгә куючы – Казан (Идел буе) федераль университеты
Редакция һәм нәшрият адресы: 420021, Казан ш., Профессор Нужин ур., 1/37, 318 каб.
Хәбәрләшү өчен телефон: 233-70-04.
Электрон почта: darelfonyn@mail.ru

Газета Федераль элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә 2012 елның 13 мартында ПИ № ТУ 16-00696 нчы таныклык белән теркәлде.
Бастырылуга кул кую вакыты: график буенча – 16.00, кул куелды – 16.00. «Карти» ҖЧҖ типографиясендә басылды, Казан ш., Восстание ур., 60 й.